КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 март г.Казань № 187

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турында» 2004 ел, 30 декабрь, 584 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турында» 2004 ел, 30 декабрь, 584 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 9 октябрь, 507 нче; 2009 ел, 6 апрель, 201 нче; 2009 ел, 19 июнь, 403 нче; 2011 ел, 21 гыйнвар, 33 нче; 2011 ел, 30 декабрь, 1104 нче; 2012 ел, 26 декабрь, 1151 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 938 нче; 2015 ел, 20 гыйнвар, 23 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 817 нче; 2017 ел, 15 февраль, 85 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1073 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1265 нче; 2019 ел, 9 декабрь, 1122 нче; 2020 ел, 28 декабрь, 1207 нче; 2021 ел, 1 декабрь, 1155 нче; 2022 ел, 5 ноябрь, 1180 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктның 3.2.2 пунктчасында «2023 елның 31 декабренә» сүзләрен «2024 елның 31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта:

4.1.1 пунктчаның беренче абзацында «2023 елның 31 декабренә» сүзләрен «2024 елның 31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.2 пунктчада:

беренче абзацта «2023 елның 31 декабренә» сүзләрен «2024 елның 31 декабренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «2023 елның 31 декабренә» сүзләрен «2024 елның 31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

5.15 пунктта «2023 елның 31 декабренә» сүзләрен «2024 елның 31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Дәүләткә карамаган пенсия түләүне туктатып тору,
яңадан башлау, туктату тәртибе, сроклары

6.1. Катнашучыга дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия түләү инвалидлык төркеменнән төшерелгән очракта туктатыла.

6.2. Әлеге Нигезләмәнең 6.1 пунктында күрсәтелгән очракта, Катнашучы вакыйга булган көннән алып 10 көн эчендә бу хакта Фондка язмача хәбәр итәргә тиеш.

6.3. Дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия түләү әлеге Нигезләмәнең 6.2 пункты нигезендә Катнашучының хәбәре Фондка кергән айдан соң килә торган айның 1 нче көненнән туктатыла.

6.4. Катнашучы әлеге Нигезләмәнең 6.2 пунктында каралган йөкләмәләрне үтәмәгән һәм шуңа бәйле рәвештә дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсиянең артык суммасын алган очракта, Катнашучы артык түләнгән суммаларны Фондка кире кайтарырга тиеш.

6.5. Әлеге Нигезләмәнең 6.1 пункты нигезендә дәүләтнеке булмаган (өстәмә) пенсия түләү туктатылган Катнашучылар, инвалидлык билгеләнгәндә, әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия түләүне кабат билгеләү хокукына ия була.

Дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсияне түләүне кабат билгеләү өчен Катнашучы Фондка дәүләткә карамаган пенсия түләүне дәвам итү турында гариза һәм инвалидлык билгеләү турында белешмә күчермәсен эш урыны буенча оешманың кадрлар хезмәтендә яки дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия билгеләү турында гариза бирү урыны буенча, яшәү урыны буенча яки нотариаль рәвештә раслап җибәрергә тиеш.

Катнашучыга дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсияне кабат түли башлау, югарыда күрсәтелгән документлар Фондка кергән айдан соң килә торган айдан да соңга калмыйча, Фонд тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.6. Катнашучы ел саен, 1 октябрьдән алып 1 декабрьгә кадәр, Фондка эш урыны буенча оешманың кадрлар хезмәтендә яисә дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия билгеләү турында гариза бирү урыны буенча, яшәү урыны буенча яисә нотариаль рәвештә расланган паспорт, хезмәт кенәгәсенең беренче һәм соңгы битләре күчермәләрен һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә, шулай ук әгәр яңадан тикшерү срогыннан чыгып билгеләнгән булса инвалидлыкны билгеләү турында хакыйкый белешмә кәгазен җибәрергә тиеш.

6.7. Фондка әлеге Нигезләмәнең 6.6 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләрен җибәрмәгән Катнашучыларга дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсияләр түләү чираттагы елның 1 гыйнварыннан туктатыла.

6.8. Әлеге Нигезләмәнең 6.7 пунктында күрсәтелгән Катнашучыларга дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия түләүне яңарту Фонд тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 6.6 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләре Фондка кергән айдан соң килә торган айдан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсияне түләү, Катнашучы эшкә урнашкан очрактан тыш, соңгы туктап тору көненнән пенсия түләү туктатылган барлык чор өчен башкарыла.

Катнашучы эшкә урнашкан очракта, дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсияне түләү эшкә урнашкан айга кадәр (әлеге айны кертеп) соңгы туктатып тору датасыннан пенсия түләү туктатып торылган чор өчен башкарыла.

6.9. Дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия түләүне туктатып тору чоры түләүләр чоры озынлыгына кертелә.

6.10. Дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсияне түләү түбәндәге очракларда туктатыла:

Катнашучы вафат булу;

Катнашучы (пенсионерны) картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортка (пансионатка) урнашу, попечительлекне рәсмиләштерү;

суд карары белән Катнашучыга иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза билгеләнү;

Катнашучы «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон белән каралмаган пенсия төрен сайлау;

Катнашучы эшкә урнашу.

6.11. Әлеге Нигезләмәнең 6.10 пунктындагы өченче – алтынчы абзацларында күрсәтелгән очракларда, Катнашучы вакыйга булган көннән алып 10 көн эчендә бу хакта Фондка язмача хәбәр итәргә тиеш.

6.12. Дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия түләү дәүләтнеке булмаган (өстәмә) пенсияне түләүне туктатуга китерерлек шартлар туган айдан соң килә торган айның беренче көненнән дә соңга калмыйча туктатыла.»;

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Нигезләмәнең 6.6 пункты (хезмәт кенәгәсенең беренче һәм соңгы битләре күчермәләрен һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәткодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне җибәрү өлешендә), 6.8 пунктындагы өченче абзацы, 6.10 пунктындагы алтынчы абзацы, 6.11 пункты, Нигезләмәнең әлеге карар редакциясендәге 1 нче кушымтасы Нигезләмә нигезендә дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия алу хокукы беренче тапкыр әлеге карар үз көченә керү датасыннан башлап барлыкка килгән Катнашучыларга карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 26 март, 187 нче карары редакциясендә)

Форма

________________________________________
(оешма исеме)
җитәкчесе _________________________ га (ка)
(җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
________________________________________
________________________________________
(фамилиясе)
________________________________________
(исеме)
______________________________ дан/(нан)
(атасының исеме (булганда))
Туган көне ____________________________
(көне) (ае) (елы)
Шәхесне раслый торган документ:
_______________ _______ ________________
(исеме) (серия) (номер)
Кем биргән ____________________________
Кайчан бирелгән ________________________
Яшәү адресы ___________________________
(индекс, район,
________________________________________
шәһәр, урам, йорт, төзелмә, фатир)
Телефоны ___________________________
Салым түләүченең ИННы__________________

Гариза

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 584 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) буенча миңа вәкаләтле дәүләткә карамаган пенсия фондында (алга таба – Фонд) дәүләтнеке булмаган пенсия түләүне билгеләвегезне сорыйм.

Түләүләрне түбәндәгечә башкаруыгызны сорыйм (кирәклесен тутырырга):
______________________________________________________________________
________________________________________________ адресы буенча Фонд кассасына акчалата;
______________________________________________________________________
____________________________________________________________ адресына почта аша күчереп;
_____________________________________________________________ номерлы счет,
(банк бүлегенең исеме, урнашу урыны)
______________________ номерлы корреспондент счеты, ______________ исәп-хисап счеты,

БИК _____________________________, банк ИННы ______________________________,

гариза бирүченең банктагы шәхси счетына ___________________________________ күчереп.

_______________________
(гариза бирүченең имзасы)

Нигезләмәнең 6.6 пункты нигезендә ел саен, 1 октябрьдән алып 1 декабрьгә кадәр, Фондка эш урыны буенча оешманың кадрлар хезмәтендә яисә дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия билгеләү турында гариза бирү урыны буенча, яшәү урыны буенча яисә нотариаль рәвештә расланган паспорт, хезмәт кенәгәсенең беренче һәм соңгы битләре күчермәләрен һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1]статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә, шулай ук әгәр яңадан тикшерү срогыннан чыгып билгеләнгән булса инвалидлыкны билгеләү турында хакыйкый белешмә кәгазен җибәрергә тиешлегем турында беләм.

_______________________
(гариза бирүченең имзасы)

Эшкә урнашкан очракта, дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия түләүне туктату турында, шулай ук түбәндәге очракларда хәбәрдармын:

картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортка (пансионатка) урнашкан, попечительлек рәсмиләштерелгән;

суд карары буенча иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза билгеләнгән;

«Иминият пенсияләре турында» Федераль закон белән каралмаган пенсия төре сайланган;

һәм әлеге вакыйгалар башланган көннән алып 10 көн эчендә бу турыда Фондка язмача хәбәр итәргә.

_______________________
(гариза бирүченең имзасы)

Гариза бирү датасы _____ ел, «___» _________

Оешманың кадрлар хезмәте тарафыннан тутырыла

Фамилиясе ____________________________________________________________

Исеме ________________________________________________________________

Атасы исеме (булганда) ________________________________________________

_____________________________________________ бәйле рәвештә эштән азат ителде

_____ елның «___» __________ дагы ____________ номерлы боерыгы.

Гариза бирүченең хезмәт шартнамәсе өзелгән вакытка Татарстан Республикасы бюджет өлкәсендә өзлексез эш стажы _____________________________________ тәшкил итә
(тулы еллар саны)

Кадрлар хезмәтенең вазыйфаи заты _________________________________________
(вазыйфасы)

_________________ _____________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

_________________________